**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Шешминка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авылы составына керүче Шешминка Крепосте авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

08 ноябрь 2019 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 08 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Андреевка торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймалар урнаштыру, ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте торак пунктында суүткәргеч челтәрләренең проект һәм эзләнү эшләре (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре,проект экспертизасы), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте, Андреевка, Павловка, Нагай торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте һәм Андреевка торак пунктларында юл челтәрен кышкы чорда карап тоту һәм җәйге чорда чабу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

“Әйе” “Юк”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 275 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 153 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 147 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен 6 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:
1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегендә халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.
2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:
- Андреевка торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймалар урнаштыру, ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте торак пунктында сууткәргеч челтәрләренең проект һәм эзләнү эшләре (инженерлык эзләнүләре, проект эшләре,проект экспертизасы), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте, Андреевка, Павловка, Нагай торак пунктларында урам утларын ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Шешминка крепосте һәм Андреевка торак пунктларында юл челтәрен кышкы чорда карап тоту һәм җәйге чорда чабу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу - карар кабул ителгән дип танырга.
3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Шешминка авыл җирлеге башлыгы: М.Д.Шәйхетдинов